# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**28.11.2024ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән, МХО зонасында хезмәт итүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- торак пунктлар эчендәге гомуми кулланыштагы автомобиль юлларын карап тору, төзекләндерү (Кызыл Төбәк торак пункты Ю.Гагарин һәм Пионерская урамнарына вак таш (щебень) сатып алу, ташу һәм салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- урам утлары төзелеше (Кызыл Төбәк торак пунктында лампалар, энергия саклагыч светильниклар, электр товарлары сатып алу, урнаштыру, аларга агымдагы ремонт һәм карап тору, килешү буенча түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иркәнәш торак пунтында сабантуй урынын җыештыру, скамейкалар, будка алу, урнаштыру, килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы

Камалов И. З.